| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| ГЛАВА<br>СТЕПНООЗЕРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | БИКҮЛЕ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ НУРЛАТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ |
| 423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная,<br>дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34 | 423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур.,<br>23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34 |

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 26 октябрь 2020 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 12 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы буенча 19нчы йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында Мәктәп урамы, Дружба урамы, Ленин урамы буенча, М. Җәлил урамы буенча 23-51, № 52-62 йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 12 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Ш. Камал урамы, 2 нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында Гагарин ур., Ш. Камал ур., Шоссейная урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта М.Җәлил урамы буенча 32нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авылында Зеленая урамында яшәүче, Бикүле авылындагы М. Җәлил урамы буенча 2-50 нче йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2020 елның 14 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Тукай урамы буенча 14 нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында М. Җәлил урамы, Тынычлык урамы, Х. Такташ урамы, Тукай урамында яшәүче

гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Бикүле авылында яшәүчеләр исемлеген гражданнар җыенын уздыру өчен сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бикүле авылындагы 3нче номерлы зират коймасын ремонтлау һәм карап тоту;

- Бикүле торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау;

(грунт-вак таш катнашмасы һәм вак таш җәю, сатып алу, ташу, җәю)

« РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М. Шакирова